Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге составына керүче Сосновый Бор поселогы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«14» апрель 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. Үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге составына керүче Сосновый Бор поселогы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 18 декабрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«-тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Сосновый Бор торак пунктында урам яктыртуын ремонтлау өчен электр җиһазлары һәм комплектлау элементлары (яктырткычлар) урнаштыру, сатып алу)»;

«-урам яктырту эшләрен башкару (Сосновый Бор торак пунктында СИП-кабель җәю)»;

«-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау, вак таш һәм асфальт валчыклар сатып алу, махсус техника хезмәтләре, А. Алеев урамы, А . Ефимов урамы буенча Сосновый Бор торак пунктында)»;

«-су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Сосновый Бор торак пунктында сууткәргеч ремонтлау)»;

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 18 декабрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Сосновый Бор гражданнар җыены карарына:

«-тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Сосновый Бор торак пунктында урам яктыртуын ремонтлау өчен электр җиһазлары һәм комплектлау элементлары (яктырткычлар) урнаштыру, сатып алу)»;

«-урам яктырту эшләрен башкару (Сосновый Бор торак пунктында СИП-кабель җәю)»;

«-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау, вак таш һәм асфальт валчыклар сатып алу, махсус техника хезмәтләре, А. Алеев урамы, А . Ефимов урамы буенча Сосновый Бор торак пунктында)»;

«-су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Сосновый Бор торак пунктында сууткәргеч ремонтлау)»;

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында,

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru), Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Кнәз авыл җирлеге советы рәисе,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Кнәз авыл җирлеге Башлыгы Ф.Ф.Хафизова